| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ ХОЗЕСАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ХУҖА ХӘСӘН АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 августа 2025г. Хуҗа Хәсән ав. № 9

Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге территориясендә файдаланылган терекөмешле лампалар туплау урынын булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» 2023 елның 05 апрелендәге 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) турында нигезләмәне раслау хакында» 2024 елның 14 мартындагы 300 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге территориясендә файдаланылган терекөмешле лампалар туплау урынын булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» 2023 елның 05 апрелендәге 16 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге территориясендә, әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән, файдаланылган терекөмешле лампалар туплау урынының урнашуы турында кулланучыларга мәгълүмат бирергә.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникацион челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» һәм http://hozesan-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Хуҗа Хәсән авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе С.П.Матвеева